| ГЛАВА АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2024 п.г.т. Алексеевское № 95

**Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 10.03.2020 ел, № 19 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча Ведомствоара комиссия турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Кадрлар алмашынуга бәйле рәвештә һәм Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 10.03.2020 ел, № 19 карары белән расланган Алексеевск муниципаль районында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча Ведомствоара комиссия турында Нигезләмәнең 1.2. пунктына туры китереп,

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 10.03.2020 ел, № 19 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча Ведомствоара комиссия турында» карарына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымта) бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе О. Н.Леденцовка йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С. А. Демидов**

Алексеевск муниципаль
районы Башлыгының
12.12.2024 ел, № 95
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында экологик куркынычсызлык,табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча Ведомствоара комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Язынин Р.С. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе; |
| Хөснетдинов Р.Р. | Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Чистай, Спас, Алексеевск, Яңа Чишмә районнарында территориаль бүлеге башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары (килештерү буенча); |
| Хәмзина Е.А. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Кулагина Т.Е. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты Аппаратының баш белгече, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Кәбиров Р.Р. | Алексеевск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, табигатьне саклау, экология һәм җирдән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе (килештерү буенча); |
| Сибгатуллин Р.Р. | «Биләр урман хуҗалыгы» ДБУ директоры (килештерү буенча); |
| Хәйбуллин Х.Х. | «Алексеевск районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ башлыгы (килештерү буенча); |
| Мусин Г.К. | Алексеевск муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килештерү буенча); |
| Әхмәтҗанов Р.Р. | Татарстан Республикасы Алексеевск районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге башлыгы (килештерү буенча); |
| Мишечкин В.Г. | «Татарстан Республикасы буенча 7 ФЯКХО» ФДКУнең 104 нче ЯКЧ башлыгы (килештерү буенча); |
| Фәсахова А.Р. | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы вазыйфаларын башкаручы (килештерү буенча); |
| Леденцов Н.И. | «Алексеевск инженерлык челтәрләре » ҖЧҖ генераль директоры (килештерү буенча); |
| Свистунов И.К. | Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча); |
| Белова Г.В. | Алексеевск муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |

| | |
|---|---|
| Галлямов И.М. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Идел-Кама территориаль Идарәсенең 3 разрядлы өлкән белгече (килештерү буенча); |
| Рузанов А.И. | Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге башлыгы (килештерү буенча). |

**Советның аппарат җитәкчесе** **А.Г. Соловьев**